РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**“ТАТАР ДӘҮЛӘТ ГУМАНИТАР-ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ”**
ЮГАРЫ ҺӨНӘРИ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

Татар филологиясе факультеты

Гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасы

# ФӘННИ-МЕТОДИК МИРАС: ТЕЛЛӘРНЕ ЧАГЫШТЫРЫП ӨЙРӘНҮ

*студентлар һәм укытучылар өчен*
*уку әсбабы*

КАЗАН 2011

“Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты” югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесенең гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасы карары нигезендә басыла.

УДК 811.512.145:811.16.1

ББК 81.2Тат-2:81.2Рус-2
С-21

Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү. Студентлар һәм укытучылар өчен уку әсбабы / Төз.: М.Р.Саттарова. – Казан: Вестфалика, 2011. - 44 б.

Әлеге уку әсбабы дәүләт белем стандартының 050302 “Туган (татар) тел һәм әдәбият” белгечлеге буенча югары уку йортларының көндезге һәм читтән торып уку бүлегендә “Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү” курсын өйрәнүче студентлар өчен төзелде. Бу әсбабтан шулай ук педагогика көллияте студентлары һәм мәктәп укытучылары да файдалана ала.

**Төзүчеләр:**
М.Р. Саттарова, филология фәннәре кандидаты, доцент
Д.Х. Хөснетдинов, филология фәннәре кандидаты, өлкән укытучы

**Фәнни редакторы:**
Р.Р. Җамалетдинов, филология фәннәре докторы, профессор

**Рецензентлар**:
Р.С.Нурмөхәммәтова, филология фәннәре кандидаты, доцент (ТДГПУ)
З.Ә.Исхакова, филология фәннәре кандидаты (ТӘҺСИ)

# КУРСНЫҢ ҮРНӘК ПРОГРАММАСЫ

## Курсның максат һәм бурычлары

Татар һәм рус телләрен өйрәнү, өйрәтү өлкәсендә дә күп кенә галимнәр эшләгән. “Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү” курсының **максаты** – татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнгән галимнәрнең фәнни-методик эшчәнлеген өйрәнү.

Уку-укыту барышында түбәндәге **бурычларны** чишү күз алдында тотыла:

– татар һәм рус телләрен өйрәнү, өйрәтү максатыннан татар, рус телләрендә язылган грамматикалар, сүзлекләр, үзөйрәткечләр турында фәнни мәгълүмат бирү;

– булачак татар теле һәм әдәбияты укытучыларында татар һәм рус телләре грамматикаларын, сүзлекләрен һәм үзөйрәткечләрен анализлау буенча белем һәм күнекмәләр системасы булдыру, әлеге телләргә һәм шушы телләрдә сөйләшүче халыкларга мәхәббәт, хөрмәт тәрбияләү;

– студентларны тел белеменең әлеге өлкәсенә караган терминнар белән таныштыру, аларда фәнгә, фәнни-методик мирасыбызга карата кызыксыну уяту.

“Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү” курсының **өйрәнү объекты** – ике телнең фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләрен тасвирлап язылган фәнни, методик хезмәтләр, сүзлекләр. “Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү” курсы студентларны алдагы семестрда укылачак “Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләре)” дисциплинасын үзләштерүгә әзерләү максатыннан укытыла.

Курс туган (татар) тел һәм әдәбият укытучыларының түбәндәге һөнәри эшчәнлек төрләрен күздә тота:

*укыту-тәрбия эшчәнлеге өлкәсендә:*

- укыту процессын белем бирү программасына туры китереп оештыру;
- программадагы дәресләрне тема һәм бүлекләрнең үзенчәлекләрен истә тотып һәм уку планына туры китереп планлаштыру һәм үткәрү;
- фәнни нигезләнгән заманча уку-укыту алымнары, метод һәм чараларыннан файдалану;
- техник чараларны, мәгълүмати һәм компьютер технологияләрен куллану;

- уку-укыту нәтиҗәләрен бәяләүдә заманча чараларны куллану;

- укучыларда рухи, әхлакый кыйммәтләр һәм ватандарлык карашлары тәрбияләү;

- аудиториядән тыш мероприятиеләр оештыру һәм үткәрү.

*фәнни-методик эшчәнлек өлкәсендә:*

- фәнни-методик эшләр башкару, фәнни-методик берләшмәләрнең эшендә катнашу;

- квалификацияне күтәрү һәм камилләштерү максаты белән үз эшчәнлегеңә анализ ясау.

*мәдәни-агарту эшчәнлеге өлкәсендә:*

- укучыларда гомум культура формалаштыру.

## Курсның эчтәлеген үзләштерү дәрәҗәсенә таләпләр

Курсны өйрәнү нәтиҗәсендә студентлар Россиядә татар телен өйрәнә һәм өйрәтә башлау, аның сәбәпләре, татар грамматикалары төзелү тарихы турында, татар аудиториясендә рус теле укытылуның тарихы, үзенчәлекләре хакында мәгълүмат алырга; чагыштырма грамматикаларның төзелешен күзалларга, рус-татар һәм татар-рус телләрен чагыштырма планда өйрәнгән галимнәрнең фәнни-методик эшчәнлекләре һәм аларның төп хезмәтләре белән танышырга тиеш.

## Курсның эчтәлеге

Кереш. Россия дәүләтендә мәгариф системасының үсеш күрсәткечләре буларак югары уку йортлары, гимназияләр, басмаханәләр ачылу. Россиянең Урта һәм Көнчыгыш Азия дәүләтләре белән багланышларында татар теленең тоткан урыны.

Россия уку йортларында төрки телләр укыту торышы (XVIII-XX г. башы). Әлеге юнәлештә эшчәнлек алып барган галимнәрнең (Хәлфиннәр династиясе, Г.Мәхмүдов, С.Кукляшев, Г.Бикмиев, Г.Ваһапов, М.Казем-Бәк, М.Иванов, М.Бикчурин һ.б.) тормыш юлы һәм эшчәнлегенә күзәтү.

XIX гасыр-XX гасыр башында рус телендә һәм рус грамматикалары үрнәгендә рус телле укучылар өчен төзелгән татар грамматикалары (И.Гиганов, 1801; И.Хәлфин, 1809; А.Троянский,

1814, 1860; М.Казем-Бәк 1839, 1846; М.Иванов 1842; И.Березин 1846; Г.Мәхмүдов 1857; К.Насыйри 1860; Х.Фәезханов 1862; А.Воскресенский 1894; Ш.Әхмәров 1895; Кондратов 1908; Юнусов 1911; Н.Ильминский 1914; А.Самойлович 1916);). Аларга гомуми характеристика, үсеш-үзгәреш үзенчәлекләре.

Фәнни-методик мирасның әһәмиятле өлеше буларак татар-рус, рус-татар сүзлекләре, татар теленең аңлатмалы һ.б. сүзлекләре. Үзөйрәткечләр. Аларның төзелү принциплары, методик кыйммәте.

Рус тел белемендә грамматикалар төзелү тарихына күзәтү. Иң әһәмиятле хезмәтләр турында кыскача мәгълүмат (М.Смотрицкий, 1619, 1648; М.Ломоносов, 1755; Ф.Буслаев, 1858; А.Потебня, 1874; Ф.Фортунатов, 1901; А.Шахматов, 1941; Л.Щерба 1957; В.Виноградов 1972; “Русская грамматика”, 1980 һ.б.).

XIX гасыр-XX гасырның 10 нчы елларында татарлар өчен татар телендә гарәп грамматикаларына ияреп төзелгән грамматикалар (Г.Фәезханов, 1887; К.Насыйри, 1895; М.Ахундов, 1897; Г.Начиз, 1900; М.Өметбаев, 1901; Ә.Мөхәмәдрәхим, 1905; 1908, Х.Мәккәи, 1907, 1912; Х.Кәбүтәри, 1910 һ.б.). Бу хезмәтләрдә терминология кулланылышының үзенчәлекләре. Татар телендә дөнья күргән әлеге хезмәтләргә гомуми характеристика.

Татар теленең төзелешен рус һәм гарәп грамматикаларына иярмичә, үзенчәлекле юл белән тасвирлап, татарча язылган грамматикалар басылу (Ш.Иманаев, 1910; Ә.Максуди, 1910; Г.Нугайбәк, 1911; Г.Ибраһимов 1913, 1915, 1918; Г.Сәгъди, 1915; Җ.Вәлиди, 1919; М.Корбангалиев, 1918, 1919; Р.Газизов, 1923; Г.Алпаров 1926 һ.б.).

XX гасырда төзелгән чагыштырма грамматикалар. Аларга гомуми күзәтү ясау. Бу хезмәтләрнең төзелеше. Аларда ике телнең (татар, рус) фонетик, морфологик, синтаксик төзелеше буенча мәгълүмат бирелүе. Бу грамматикаларда кулланылган терминология мәсьәләсе. Әлеге хезмәтләрнең авторлары турында мәгълүмат (А.А.Әминова, Л.К.Бәйрәмова, З.М.Вәлиуллина, Р.Газизов, Р.Р.Җамалетдинов, М.З.Зәкиев, К.З.Зиннәтуллина, М.Корбангалиев, Ф.Ф.Харисов, Л.З.Шакирова һ.б.).

XX гасырның икенче яртысыннан башлап, бүгенге көннәргә кадәр татар тел белемен үстерүдә көч куйган галимнәр, аларның тормыш юлы, фәнни эшчәнлеге, хезмәтләре (Ә.М.Ахунҗанов, Ф.С.Сафиуллина, Д.Г.Тумашева, Ч.М.Харисова, Р.А.Юсупов һ.б.ларның тормышы һәм фәнни-методик эшчәнлегенә күзәтү ясау.

## Курсның укыту-методик тәэмин ителеше

Тәкъдим ителә торган әдәбият

*а) төп әдәбият*

Баскаков, Н.А. Введение в изучение тюркских языков / Н.А.Баскаков. – М., 1969.

Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З.Закиев. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2008.

Мифтахова, И. История татарских грамматик XIX-нач. XX в. (в 2-х частях) / И.Мифтахова. - К.: Хәтер, 1998, 1999.

*б) өстәмә әдәбият*

Аминова, А.А. Производный глагол в сопоставительном аспекте: На материале русского и татарского языков / Научный ред.Ф.А.Ганиев. – Изд-во Казан.ун-та, 1993.

Ахунзянов, Э.М. Двуязычие и лексико-семантическая интерференция / Э.М.Ахунзянов. – Казань: Изд-во КГУ, 1978.

Ахунзянов, Э.М. Контрастивная грамматика: морфология русского и тюркских языков: Учебное пособие / Э.М.Ахунзянов. – Казань: Изд-во КГУ, 1987.

Байрамова, Л.К. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / Л.К.Байрамова. – Зеленодольск: Дело, 1997.

Байрамова, Л.К. Татарстан: языковая симметрия и асимметрия / Л.К.Байрамова. – Казань: Изд-во КГУ, 2001.

Бәдигый, Х. Татар теленең сарыф һәм нәхүе / Х.Бәдигый. – Казан, 1917.

Березин, И.Н. Дополнение к тюркской грамматике / И.Н.Березин. – СПб., 1846.

Березин, Ф.М. История советского языкознания. Хрестоматия / Ф.М.Березин. – М., 1981.

Богородицкий, В.А. Введение в татарское языкознание / В.А.Богородицкий. – Казань, 1953.

Валеев, Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX -20-е гг. XX вв.) / Р.М. Валеев. - Казань: Изд-во КГУ, 1998.

Валиуллина, З.М. К истории сопоставительного изучения татарского и русского языков / З.М.Валиуллина.- К., 1971.

Вәлиди, Җ. Татар теленең имля, сарыф вә нәхү кагыйдәләре /

Җ.Вәлиди. – Казан, 1915.

Газизов, Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков / Р.Газизов.- К.: Таткнигоиздат, 1966.

Гиганов, И. Грамматика татарского языка, сочиненная в Тобольской главной школе учителем татарского языка, священником Иосифом Гигановым и мулламаи Юртовскими свидетельствованная / И.Гиганов. – СПб.: Акад.наук, 1801.

Җамалетдинов Р.Р. Татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнү: Укыту-методик кулланма / Р.Р.Җамалетдинов. – Казан: КДПУ, 2002.

Җамалетдинов, Р.Р. Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы: Дәреслек-кулланма / Р.Р.Жамалетдинов. - Казан: КДУ нәшр., 2004.

Җамалетдинова, Г.Ф. Ризаутдин Газизов: лингвистическое и методическое наследие / Г.Ф.Жамалетдинова. - К., Магариф, 2005.

Закиев, М.З., Сафиуллина, Ф.С., Зиннатуллина, К.З., Ибрагимов, С.М. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков: В 3-х ч. / М.З.Закиев, Ф.С.Сафиуллина, К.З.Зиннатуллина и др. – Казань, 1977.

Закирова, М.З. Исторический обзор развития грамматики татарского языка: Автореф. дис... канд. филол. наук. / М.З. Закирова. - Казань, 1951.

Ибраһимов, Г. Татар нәхүе / Г.Ибраһимов. – Казан, 1911.

Ибраһимов, Г. Татар сарыфы / Г.Ибраһимов. – Казан, 1911.

Иванов, М. Татарская грамматика. В 2-х томах: Грамматика. Хрестоматия / М.Иванов. – Казань, 1842.

Иманаев, Ш. Татар теленең сарыфы вә нәхүе / Ш.Иманаев. – Казан, 1910.

Казем-Бек, А. Общая грамматика турецко-татарского языка./А. Казем- Бек. – Казань, 1846.

Кононов, А.Н. Из истории татарского языкознания: татарская грамматика И.Гиганова (1801) // Выдающийся просветитель – демократ Каюм Насыри / А.Н. Кононов. - Казань, 1976. - С. 69-78.

Курбангалиев, М.Х., Газизов, Р.С. Опыт систематической грамматики татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка / М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов. - К.: Татгосиздат, 1931.

Максуди, Ә. Төрки сарыф / Ә.Максуди. – Казан, 1910.

Максуди, Ә. Төрки нәхүе / Ә.Максуди. – Казан, 1910.

Махмудов, М. Практическое руководство к изучению

татарского языка / Г.Махмудов. – Казань, 1857.
Насыйри, К. Әнмүзәҗ / К.Насыйри. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1975.
Нугайбәк, Г. Төрлек / Г.Нугайбәк. – Казан, 1916.
Өмидбаев, М. Татар нәхүсенең мөхтәсәре / М.Өмидбаев. – Казан, 1901.
Рәми, И., Даутов, Р. Әдәби сүзлек (элекке чор татар әдәбияты һәм мәдәнияте буенча кыскача белешмәлек) / И.Рәми, Р.Даутов. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.
Сафиуллина, Ф.С., Байрамова, Л.К. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков / Ф.С.Сафиуллина, Л.К.Байрамова. – Казань: Изд-во КГУ, 1998.
Сафиуллина, Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре / Ф.С.Сафиуллина. - К.: Хәтер, 2001.
Сәгъди, Г. Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыфы / Г.Сәгъди. – Казан, 1913.
Сәгъди, Г. Үз телемезгә мөкәммәл сарыф, нәхү / Г.Сәгъди. – Казан, 1915.
Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы / Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы. 2004 – 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Респбуликасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.
Троянский, А. Краткая татарская грамматика, в пользу учащегося юношества, сочиненный Казанской Академии учителем татарского языка священником А.Троянским / А.Троянский. – СПб, 1814.
Фәезханов, Г. Татар телигә кыскача гыйльме сарыф / Г.Фәезханов. – Казан, 1887.
Фейзханов, Х. Краткая учебная грамматика татарского языка / Х.Фейзханов. – СПб, 1862.
Харисов, Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному / Ф.Ф.Харисов. - СПб, 2002.
Харисова Г.Ф. Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты һәм аның галимнәре / Г.Ф.Харисова. – Казан, 2009.
Харисова, Ч.М. Обучение татарскому произношению в русской

школе / Ч.М.Харисова. – М.: Владос, 2001.

Хальфин, И. Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения / И.Хальфин. – Казан, 1809.

Шакирова, Л.З. Основы методики преподавания русского языка в татарской школе / Л.З.Шакирова. – Казань: Мәгариф, 1999.

Юсупов, Р.А. Әдәп башы – тел / Р.А.Юсупов. К.: КДПУ, 2000.

Юсупова А.Ш. Самоучители татарского языка XIX века. Лексика / А.Ш.Юсупова. – Казань: Школа, 2002. – 140 с.

## Курсның материаль-техник тәэмин ителеше

Студентларның бу курсны уңышлы үзләштерүен тәэмин итү өчен, түбәндәгеләрне булдырырга кирәк:

- тиешенчә җиһазландырылган аудитория;

- техник чаралар (аудио- һәм видео аппаратлар), күрсәтмә материаллар, русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләр.

## Йомгаклау һәм агымдагы контроль эчтәлеге

*Зачет өчен якынча сораулык*

1. Россиядә татар телен өйрәнү тарихы.
2. Руслар тарафыннан татар телен өйрәнә башлауның объектив сәбәпләре.
3. XIX-XX гасырларда Россиянең татар теле укытылган уку йортлары турында мәгълүмат.
4. Татар теле грамматикаларының максаты һәм төзелеше ягыннан төркемнәре.
5. Рус теле грамматикалары үрнәгендә рус телле укучылар өчен төзелгән әсбаплар.
6. Гарәп грамматикасы нигезендә төзелгән татар грамматикалары.
7. Татар-рус телен өйрәнүдә үзөйрәткечләрнең әһәмияте.
8. Рус һәм гарәп грамматикаларына иярмичә язылган татар телле грамматикалар.
9. Рус грамматикалары үрнәгендә төзелгән мәктәп дәреслекләре һәм аларның авторлары.

10. Фонетика, морфология, синтаксис бүлекләреннән торган дәреслекләр һәм аларның авторлары.

11. Татар һәм рус тел белемнәрендә сүз төркемнәренең өйрәнелү тарихына кыскача күзәтү.

12. Татар һәм рус телләренең фонетика мәсьәләләрен өйрәнгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.

13. Татар һәм рус телләренең лексикология мәсьәләләрен өйрәнгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.

14. Татар һәм рус телләренең морфология мәсьәләләрен өйрәнгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.

15. Татар һәм рус телләренең синтаксис мәсьәләләрен өйрәнгән галимнәр һәм аларның хезмәтләре.

16. Татарларга рус телен өйрәтү юнәлешендә эшләгән галимнәр.

17. Русларга татар телен өйрәтү юнәлешендә эшләгән галимнәр.

18. Бүгенге көндә Татарстанда тел сәясәте.

19. Татар һәм рус телләрендә сүзлекләр.

20. Үзөйрәткечләр һәм телләрне чагыштырма аспектта өйрәнүдә аларның әһәмияте.

*Реферат өчен темалар*

1. Ә.Ахунҗановның фәнни-методик эшчәнлеге.
2. А.Әминованың фәнни-методик эшчәнлеге.
3. Л.Бәйрәмованың фәнни-методик эшчәнлеге.
4. З.Вәлиуллинаның фәнни-методик эшчәнлеге.
5. Р.Газизовның фәнни-методик эшчәнлеге.
6. И.Гигановның фәнни-методик эшчәнлеге.
7. Р.Р.Җамалетдиновның фәнни-методик эшчәнлеге.
8. М.Зәкиевнең фәнни-методик эшчәнлеге.
9. К.Зиннәтуллинаның фәнни-методик эшчәнлеге.
10. А.Казем-Бәкнең фәнни-методик эшчәнлеге.
11. М.Корбангалиевның фәнни-методик эшчәнлеге.
12. К.Насыйриның фәнни-методик эшчәнлеге.
13. Ф.Сафиуллинаның фәнни-методик эшчәнлеге.
14. А.Троянскийның фәнни-методик эшчәнлеге.
15. Ф.Харисовның фәнни-методик эшчәнлеге.
16. И.Хәлфинның фәнни-методик эшчәнлеге.

17. Ч.Харисованың фәнни-методик эшчәнлеге.
18. Л.Шакированың фәнни-методик эшчәнлеге.
19. Р.Юсуповның фәнни-методик эшчәнлеге.

Чыгыш әзерләгәндә һәм реферат язганда түбәндәгеләргә игътибар итү сорала:

1. Галимнең тормыш юлы һәм фәнни эшчәнлеге турында кыскача мәгълүмат бирергә;
2. Телләрне чагыштырма планда өйрәнү юнәлешендәге төп хезмәтләре, аларның үзенчәлекләренә тукталырга (гомуми мәгълүматтан кала берничә төп хезмәтне анализларга);
3. Бүгенге уку-укыту шартларында әлеге галим башкарган хезмәтләрнең әһәмияте, аларны файдалану мөмкинлекләрен күрсәтергә.

## Курсны өйрәнүне оештыруга карата методик күрсәтмәләр

“Фәнни-методик мирас: телләрне чагыштырып өйрәнү” – “Туган (татар) тел һәм әдәбият” белгечлеге буенча лингвистик циклда өйрәнелә торган курс. Әлеге курс алдагы семестрда укыла торган “Чагыштырма тел белеме” курсына әзерлек булып тора. Курсны үзләштерү булачак татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен зур әһәмияткә ия. Шул сәбәпле, татар тел белемендә, татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнгән фәнни хезмәтләрдә тупланган фикерләрне, бәхәсле булган очракларны аңлату мөһим.

Студентларның лингвистик фикерләү сәләтен һәм фактларны анализлау осталыкларын үстерү максатыннан, курс материалының төп өлеше семинар дәресләрдә үзләштерелә. Курсны өйрәнү барышында студентларның язма һәм сөйләмә рәвештә биремнәр үтәве, докладлар белән чыгышлар ясавы да күздә тотыла. Мөстәкыйль эш буларак, студентларга реферат язу өчен библиографиядә күрсәтелгән кайбер фәнни хезмәтләрне тәкъдим итәргә мөмкин. Болар барысы да әлеге курсны үзләштерергә ярдәм итәчәк.

## ТАТАР ҺӘМ РУС ТЕЛЛӘРЕН ЧАГЫШТЫРМА ӨЙРӘНҮДӘ ХЕЗМӘТ КУЙГАН ГАЛИМНӘР

Әлеге бүлектә XIX гасыр башыннан алып бүгенге көннәргә кадәр Казан лингвистика мәктәбенең нигезен салуда, торгызуда, татар телен, аның фонетик, грамматик үзенчәлекләрен, сүз ясалышын, лексик байлыгын рус теле белән чагыштырма аспектта өйрәнүгә үзләреннән җитди өлеш керткән галимнәрнең тормышы һәм эшчәнлегенә кагылышлы кыскача мәгълүмат тупланды. Материаллар “Казанская лингвистическая школа”, “Әдәби сүзлек” һ.б. чыганаклардан алынды. Авторлар, аларның хезмәтләрен тасвирлау алфавит тәртибендә тәкъдим ителә.

### АХУНҖАНОВ ӘНВӘР МӘХМҮТ УЛЫ
(1914-1986)

Әнвәр Мәхмүт улы Ахунҗанов 1914 елның 3 февралендә Уфа губернасының Бөре шәһәрендә туа. Мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул Башкортстанның көнбатышында урнашкан Баймак поселогында бакыр кою комбинатының һөнәри училищесында рус теле укытучысы булып эшли. 1932 елда Ленинград дәүләт университетының лингвистика факультетына укырга керә һәм аны уңышлы гына тәмамлый. 1945 елда Казан педагогика институтында рус теле тарихыннан лекцияләр укый. Шул ук вакытта галим СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалында эшли һәм 1955-1959 нчы елларда төзелеп, СССР ФА премиясенә лаек булган 4 томлык “Рус-татар сүзлеге”н эшләүгә үзеннән зур өлеш кертә. Бу сүзлек тәрҗемәчеләр, нәшриятта эшләүчеләр, радио һәм телевидение, мәктәп һәм вуз укытучылары өчен планлаштырыла. Хезмәт берничә мәртәбә бастырылып чыга һәм хәзер дә төп кулланма материал булып санала. 1960 елдан гомеренең соңгы көннәренә кадәр Әнвәр Ахунҗанов Казан дәүләт университетының рус теле кафедрасында эшли. “Гомуми тел белеме” (1981) дәреслеге университетлар өчен махсус кулланма буларак эшләнә һәм 1982 елда көмеш медаль белән бүләкләнә.

Ә.М.Ахунҗанов татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнүгә багышланган хезмәтләре белән дә билгеле. Болар: “Сопоставительное изучение национального своеобразия лексических единиц (на материале русского и татарского языков.

Кулланма)” (1963), “Русские заимствования в татарском языке” (1968), “О границах применения сопоставительного метода при изучении русского языка нерусскими” (мәкалә, 1974), “Двуязычие и лексико-семантическая интерференция” (1978), “Контрастивная грамматика: морфология русского и тюркских языков” (1987).

## ӘМИНОВА АЛЬМИРА ӘСХӘТ КЫЗЫ

(1942 нче елның 10 нчы мартында туган)

Әминова Альмира Әсхәт кызы Казанда туа. 1959-1965 нче елларда Казан дәүләт университеты студенты. 1967-1971 нче елларда шул ук югары уку йортының рус теле кафедрасы каршында аспирантурада белем ала. 1972 нче елда В.М.Марков җитәкчелегендә кандидатлык диссертациясе яклаганнан соң, КДУның рус теле кафедрасында эшли. 1995 нче елда “Внутриглагольная деривация в русском и татарском языках” темасына докторлык диссертациясе яклый. 1998 елдан КДУның милли мәктәптә рус теле һәм әдәбияты кафедрасы профессоры, 2002 нче елдан бүгенге көнгә кадәр үзе хезмәт иткән чагыштырма филология һәм мәдәниятара коммуникацияләр кафедрасы мөдире.

Рус теле тарихын өйрәнүдән башланган фәнни эшчәнлегендә галимә телләрне чагыштырып өйрәнүнең мөһимлеген ачыклый һәм эзләнүләренең башлангыч елларында ук кардәш славян телләрен, аннан соң рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнә. Бу юнәлештә ул Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләре Бодуэн де Куртенэ, Н.А.Крушевский, В.А.Богородицкий һ.б. тәкъдим иткән нигезләмәләрне дәвам итә. Аның “Производный глагол в сопоставительном аспекте (на материале русского и татарского языков)” (1993) китабы татар һәм рус теле фигыльләре үзенчәлекләрен өйрәнүдә әһәмиятле хезмәт булып тора. Соңгы елларда Альмира Әсхәтовна татар һәм рус телләренең этик, эстетик, эмоциональ концептларын өйрәнә. Үзенең хезмәтләре белән ул татар һәм рус телләрен структур, функциональ һәм концептуаль аспектларда чагыштырып өйрәнүгә зур өлеш кертә.

А.Ә.Әминова Россия Федерациясенең атказанган югары мәктәп хезмәткәре исеменә лаек.

**БӘЙРӘМОВА ЛУИЗА КӘРИМ КЫЗЫ**
(1935 нче елның 1 нче гыйнварында туган)

Бәйрәмова Луиза Кәрим кызы 1935 елның 1 гыйнварында хәзерге Әгерҗе районы Исәнбәй авылында хезмәткәр гаиләсендә туа. 1952 елны Казан шәһәренең 32 номерлы мәктәбен, 1957 елны Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый. 1957-60 елларда Арча районы Субаш-Аты мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы, 1960-61 нче елларда Казан шәһәре эшче яшьләр мәктәбендә француз, рус теле һәм әдәбияты укытучысы, ә аннан соң Казан дәүләт университетының рус теле һәм гомуми тел гыйлеме кафедрасында эшли. Л.К.Бәйрәмова – Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Казан дәүләт университетының лингвистика өлкәсендәге хезмәтләр арасындагы конкурсларда премияләр лауреаты, фән һәм техника өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан Республикасының дәүләт премиясе лауреаты.

Луиза Кәримовна тәрҗемә, билингвизм, социолингвистика, контрастив лингвистика, чагыштырма лексика, фразеология һәм синтаксис буенча 240 тан артык хезмәт авторы.

Татарстандагы икетеллелек проблемаларын тикшерүгә Л.К.Бәйрәмова берничә фәнни эшен багышлаган. Шуларның иң әһәмиятлесе булып “Татарстан: языковая симметрия и асимметрия” дигән монография санала. Бу хезмәттә икетеллелекне өйрәнү өлкәсендә яңа ысул тәкъдим ителә: беренчедән, симметрия һәм асимметрия кебек универсаль категорияләр аша; икенчедән, лингвистик калыплар аша үзләштерү. Луиза Кәримовна Татарстандагы икетеллелек үсешенә йогынты ясый торган тарихи, сәяси, мәдәни, лингвистик шартларны өйрәнә.

Л.К.Бәйрәмованың фәнни эшчәнлегенең тагын бер зур юнәлеше - телләрнең охшаш һәм аермалы якларын өйрәнү. Кардәш һәм кардәш булмаган телләр материалында омонимия күренешен өйрәнеп, “Ориентализмы в лексике и фразеологии болгарского языка (в сопоставлении с татарским языком)” (2007). Телләрне контрастив һәм чагыштырма аспектларда өйрәнү нәтиҗәсе буларак, “Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков” (1997), “Введение в контрастивную лингвистику” (2004) һ.б. монографияләре дөнья күрә.

## БӘДИГЫЙ ХУҖА ГАБДЕЛБӘДЫЙГЪ УЛЫ
(1887-1940)

Хуҗа Габделбәдыйгъ улы Бәдигый 1887 елда Мамадыш өязе Югары Берсут авылында дөньяга килә. “Мөхәммәдия”не тәмамлаганнан соң ул шунда ук укытырга кала. 1907 елда Казанга венгр галиме профессор Дьюла Мессарош килә. Х.Бәдигый аның белән бергә Казан арты авылларында татар әдәбияты үрнәкләре җыя. 1912-1913 нче елларда туплаган материалларын китап итеп чыгара. 1918-1926 нчы елларда Казанда укыта.

Ленинград педагогия институтында аспирантура тәмамлап, “Төрки телләрнең чагыштырма морфологиясе” дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1930 елда Казанга әйләнеп кайта һәм гомеренең ахырына кадәр Казан педагогия институтында доцент, аннан профессор буларак хезмәт итә.

Күренекле татар галиме Х.Бәдигый күпсанлы дәреслекләр авторы: “Татар теленең сарыф һәм нәхүе” (1917), “Татарча язу кагыйдәләре” (1918), шулай ук М.Корбангалиев белән авторлыкта “Ана теле сарыфы” (1918), “Ана теле нәхүе” (1919), “Шәкли нигездә гамәли тел сабаклары” (1925) исемле китаплары басылып чыга. 1923 нче елда Х.Бәдигый һәм М.Корбангалиевка татар булмаганнар өчен татар теленнән программа, дәреслекләр әзерләү бурычы куела. Шул ук елда Х.Бәдигый, М.Корбангалиев, Г.Шәрәф авторлыгында “Рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслеге” дөнья күрә. 1925-1926 нчы елларда дәреслек кабат басыла.

## БЕРЕЗИН ИЛЬЯ НИКОЛАЕВИЧ
(1818-1896)

Илья Николаевич Березин илебез тел белемен үстерүгә зур өлеш керткән XIX гасыр галимнәреннән берсе. Профессор, 1846-1855 нче елларда Казан университетының төрек-татар телләре кафедрасы мөдире, аннан соң 1855-1896 нче елларда Петербург университеты мөгаллиме. И.Н.Березин — күпкырлы шәхес. Ул педагог, фән һәм мәгариф өлкәсе хезмәткәре. Аның тарафыннан монгол, тибет, гарәп, фарсы, төрек телләрендә кульязмалар өйрәнелгән. Фәнни эшчәнлеге дәверендә А.К.Казем-Бәк, Н.И.Лобачевский, О.М.Ковалевский, Н.И.Ильминский һ.б. кебек күренекле шәхесләр белән аралашкан.

Илья Николаевич Березин үзенең остазы А.Казем-Бәк кебек үк көнчыгышны өйрәнү мәсьәләләрендә киңкырлы белгеч була. Студент булган елларында ук гарәп, фарсы һәм төрек тел белемнәре белән кызыксынган. И.Н.Березин Г.Жоберның “Төрек теле грамматикасы”н рус теленә тәрҗемә иткән. А.Казем-Бәк тәрҗемәне югары бәяли һәм үз хезмәте белән бергә туплап, “Төрек-татар теле грамматикасы” итеп төзи һәм бастыра (1839). И.Н.Березинның чираттагы хезмәте А.Казем-Бәк грамматикасына өстәмә рәвешендә “Дополнение к тюркской грамматике” исеме белән 1846 нчы елда Санкт-Петербургта басылып чыга. Автор грамматикалар төзү эшендә шул телләрдә сөйләшүчеләр катнашуның мөһимлеген әйтә.

И.Н.Березинның тагын бер әһәмиятле юнәлештә башкарылган хезмәтләре “Хан ярлыклары” (1850-1852), “Шәрыкъ тарихчылары китапханәсе” (1849-1854). Биредә автор төрки телләрдә язылган тарихи-филологик истәлекләрне анализлаган. Шәрыкъ җирләренә оештырылган экспедицияләрендә ул үзенең төрки телләрнең өч томлык хрестоматиясен төзү өчен материаллар туплаган. 1856 елда басылып чыккан 1000 мәкальнең дә күпчелеген ул шул сәяхәтләре вакытында туплаган булырга тиеш.

И.Н.Березин Казан тюркология мәктәбенең күренекле вәкиле. Аның тюркология өлкәсендә күпчелек хезмәтләре нәкъ менә Казан чорына карый.

## ВӘЛИУЛЛИНА ЗӨҺРӘ МӘҖИТ КЫЗЫ

(1925 нче елның 8 нче июнендә туган)

Зөһрә Мәҗит кызы Вәлиуллина Әлшәй районының Никифор авылында урта хәлле эшче гаиләсендә туа. Берничә елдан Бәләбәй шәһәренә күчәләр. Ленинград дәүләт педагогика университетының көнчыгыш телләр факультетына укырга керә. Аны 1949 елда тәмамлап, төрки телләр белгечлеге буенча белем ала. З.Вәлиуллинаның эшчәнлегендә төп ике юнәлешне билгеләргә мөмкин: хәзерге татар әдәби теле морфологиясе, рус һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасына караган проблемалар.

Зөһрә Мәҗитовна Вәлиуллинаның фәнни эшчәнлегендә төп юнәлеш - рус һәм татар телләрен чагыштырып өйрәнү. Бу ике телне чагыштырып тикшеренүләр нәтиҗәсе буларак 1967 нче елда “Сопоставительная грамматика русского и татарского языков” исемле монографиясе дөнья күрә. Автор бу хезмәтендә ике телнең

фонетика, морфология һәм синтаксис бүлекләрен чагыштырып, аларның һәр икесе өчен гомуми, охшаш күренешләр белән бергә, үзенчәлекле билгеләрен дә аерып күрсәтә. Үзенең фәнни эзләнүләрен тулыландыра барып, Зөһрә Мәҗит кызы 1983 елда чагыштырма грамматиканың яңа басмасын чыгара. Анда татар һәм рус телләрендәге сүз ясалышы беренче тапкыр чагыштырып тикшерелә.

Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе проблемаларын Зөһрә Мәҗит кызы күп еллар буе тирәнтен өйрәнә. Бу уңайдан аның 1972 елда К.З.Зиннәтуллина һәм М.Ә.Сәгыйтов белән авторлашлыкта "Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе" исемле зур күләмле китабы басылып чыга. Татар әдәби теленең исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш кебек сүз төркемнәре, аларның ясалыш үзенчәлекләре турында концептуаль фикерләре киң урын алган бу хезмәт шактый еллар буе галимнәр, студентлар һәм укытучылар өчен бик кирәкле, куллану өчен уңай дәреслекләренең берсе булып кала бирә. Шулай ук китапның гади, аңлаешлы тел белән язылган булуы; фәннилек, эзлеклелек, системалылык принципларына туры килерлек итеп төзелүе дә уңай тәэсир калдыра. Әлеге хезмәтендә галим һәр сүз төркеменә дә ныклап туктала, аларның үзенчәлекле якларын билгеләргә тырыша. Зөһрә Мәҗит кызы Вәлиуллинаның фикерләре бүгенге көндә дә актуаль.

## ВӘЛИДИ ҖАМАЛЕТДИН ҖӘЛӘЛЕТДИН УЛЫ
**(Җамал Вәлиди)**
(1887-1932)

Җамалетдин Җәләлетдин улы Вәлиди – тәнкыйтьче, әдәбият тарихчысы, тел белгече – 1887 нче елда элекке Тәтеш өязе Апас авылында мулла гаиләсендә туа. Иж-Бубый мәдрәсәсендә белем алганнан соң, 1911-1917 нче елларда, Оренбург шәһәрендә "Хөсәения" мәдрәсәсендә укыта. "Шура", "Вакыт" һәм башка татар матбугаты битләрендә басылып килә. 1918-1921 нче елларда Казан, Тәтеш, Арча мәктәпләрендә укыта. Инкыйлаб башланганнан соң Казанга күчеп килә. 1922-1923 нче елларда Казан университеты рабфагында укыта. 1923-1931 нче елларда Көнчыгыш педагогия институтында доцент дәрәҗәсендә хезмәт итә.

Телче буларак Җ.Вәлидине беренче чиратта татар теленең гарәп графикасы нигезендә язуы һәм орфографиясе мәсьәләләре

кызыксындыра. 1915 нче елда аның татар тел белеменә караган “Татар теленең имля, сарыф вә нәхү кагыйдәләре”, 1919, 1920 нчы елларда “Татар теленең грамматикасы” хезмәтләре дөнья күрә.

Җ.Вәлидинең татар тел белеме өлкәсендәге иң зур хезмәте – “Татар теленең тулы сүзлеге”. Бу сүзлек өчен материалларны ул Оренбургта 1911 нче елда ук туплый башлаган була. 1927-1929 нчы елларда хезмәтнең беренче ике кисәге 720 бит күләмендә басылып чыга. Калган өлешенең язмышы билгеле түгел. Җ.Вәлиди – репрессия корбаны, 1932 нче елда Казанда вафат була.

## ГАЗИЗОВ РИЗАЕТДИН СӘЛӘХЕТДИН УЛЫ
**(Риза Газизов)**
**(1894-1981)**

Газизов Ризаетдин Сәләхетдин улы 1894 елның 28 августында Турай авылында (хәзерге Алабуга районы) мулла гаиләсендә туа. 1906 елда “Ишми ишан” кадим мәдрәсәсендә укырга керә, ләкин анда булган таләпләр белән ул килешми һәм өч елдан соң Казанга китә һәм татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Октябрь инкыйлабыннан соң Р.Газизов фәнни-педагогик эшчәнлек белән ныклап шөгыльләнә башлый. 1924 елда аның М.Корбангалиев белән бергәлектә эшләгән “Грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка” хезмәте басылып чыга. 1952 һәм 1959 елларда Р.Газизов “Сопоставительная грамматика татарского и русского языков” хезмәтен бастыра. Алга таба Р.Газизов рус һәм татар балаларына укыту өчен дәреслекләр, программалар, методик ярдәмлекләр төзү белән шөгыльләнә.

XX гасырның 40 нчы елларында ул педагог-методист В.М.Чистяков белән берлектә башлангыч сыйныфлар өчен дәреслекләр төзү өстендә эшли. Алар бергәләп төзегән дәреслекләрдән “Русский язык (Букварь)”, “Русский язык: для третьего года обучения” (1946), методик ярдәмлек “В помощь учителю русского языка в начальных классах татарской школы” (1949) хезмәтләрен атап китәргә була.

Р.Газизовның лексикография өлкәсенә караган хезмәтләре булуын да билгеләп үтәргә кирәк. Гомеренең соңгы елларына кадәр ул татарча-русча, русча-татарча сүзлекләр төзү өстендә эшли. Аның 1927 һәм 1932 елларда М.Корбангалиев белән берлектә төзелгән “Татарча-русча сүзлек” (“Татарско-русский словарь”), 1950 нче

елда төзелгән “ Татарско-русский словарь”, 1947 һәм 1949 елларда М.Гимадеев белән берлектә төзелгән “Школьный русско-татарский словарь” хезмәтләре билгеле.

## ГИГАНОВ ИОСИФ ИВАНОВИЧ
## (туган елы билгесез-7.09. 1800)

XIX гасырның беренче яртысында татар телен үстерү, аның тарихын булдыруда телче галим И.И. Гигановның хезмәтләре зур урын алып тора. Гиганов Иосиф (Осип) Иванович (?-7.09.1800) күренекле рус тюркологы. Ул XVIII йөздә (туган елы билгеле түгел) Тобольск шәһәрендә туа. XVIII йөз ахырында дин әһеле буларак Тобольск шәһәренең София соборында эшли. Шул ук вакытта Тобольскның төп халык училищесында татар теле укытучысы буларак хезмәт итә.

Россиядә төрки телләрнең грамматик төзелешен һәм сүзлекләрен өйрәнү тарихында И.И.Гигановның фәнни һәм педагогик эшчәнлеге зур әһәмияткә ия. И.И.Гиганов Европада иң беренче басылып чыккан “Татар теле грамматикасы”ның авторы. Әлеге күләмле хезмәт Төмән өлкәсенең Тобольск шәһәрендә 1798 елда төзелеп бетә һәм 1801 елда Санкт-Петербургта басыла. Бүгенге көндә китап Тобольск шәһәренең дәүләт архивында саклана.

Автор әлеге хезмәтендә татар теленең авазлары турында мәгълүматлар бирә, кушымчалар ярдәмендә исемнәр ясалышын тикшерә, исемнәрдән һәм фигыльләрдән исем ясаучы берничә кушымча күрсәтә, татар телендә кушма сүзләр аз, дип яза. Кушма фигыльләргә мисаллар китерә һәм алар татар телендә күп түгел икәнен искәртә.

Бүгенге көндә тел белеме өлкәсенә караган хезмәтләрдә И.Гигановның “Татар теле грамматикасы” дип йөртелә торган хезмәтнең тулы исеме “Грамматика татарского языка, сочиненный в Тобольской главной школы учителем татарского языка, Софийского собора священником Иосифом Гигановым и муллами Юртовскими свидетельствований”.

1804 елда И.Гигановның “Тоболь халык училищесы укытучысы Гиганов тарафыннан җыелган русча-татарча сүзлек” дип аталган икенче хезмәте дөнья күрә.

И.Гигановның хезмәтләре татар теленең үсешенә зур өлеш кертә. Аның хезмәтләре бүгенге көн грамматикаларын язу өчен нигез булып тора.

**ҖАМАЛЕТДИНОВ РӘДИФ РИФКАТЬ УЛЫ**
(1969 нчы елның 27 нче октябрендә туган)

Филология фәннәре докторы, профессор, Россия табигый фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, ТДГПУ ректоры, Россия Федерациясе югары һөнәри мәгарифенең мактаулы хезмәткәре Р.Р.Җамалетинов 1969 нчы елның 27 нче октябрендә Татарстан Республикасы Чүпрәле районы Кече Чынлы авылында дөньяга килә. 1995 нче елда Казан дәүләт педагогика университетының (ТДГПУ) татар филологиясе һәм тарихы факультетын “бик яхшы” билгеләренә генә тәмамлый.

Р.Р.Җамалетдинов фәнни, педагогик, укыту-методик берләшмәләр, диссертация һәм эксперт советлары эшчәнлегендә актив катнаша. “Рус теле” һәм “Россия Федерациясе халыклары телләре (татар теле)” белгечлекләре буенча докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советы рәисе, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы педагогик белем бирү белгечлекләре буенча укыту-методик берләшмәнең Президиум әгъзасы, әлеге берләшмәгә керә торган “Туган (татар) тел һәм әдәбият” белгечлеге буенча укыту-методик комиссиянең рәисе.

Россия Президенты Указы нигезендә Р.Р.Җамалетдинов “Казанның 1000 еллыгы истәлегенә” медале белән бүләкләнә. Ул Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республика Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТДГПУның Мактау грамоталарына ия. Р.Р.Җамалетдинов – “Россия Федерациясе һөнәри мәгарифенең мактаулы хезмәткәре”, “Мәгарифтәге казанышлар өчен” күкрәк билгеләре белән дә бүләкләнә.

2007 нче елның 26 нчы декабрендә Рәдиф Рифкать улы ТДГПУ хезмәткәрләре һәм студентлары конференциясендә уку йортының ректоры итеп сайлана.

Р.Р.Җамалетдиновның фәнни-методик эшчәнлеген берничә юнәлешкә бүлеп карарга мөмкин: лингвокультурология, татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнү, татар теленә өйрәтүнең лингвометодик нигезләре өлкәләрендә эшчәнлек. Аның гомуми һәм

чагыштырма тел белеме, лингводидактика, татар лингвокультурологиясе, белем сыйфаты менеджменты системасы өлкәләренә караган 100гә якын фәнни хезмәте бар. Шуларның дистәдән артыгы монографияләр, программа һәм кулланмалар. Мәсәлән, “Лингводидактические основы обучения чтению на татарском языке учащихся начальных классов русских школ” (1999), “Сопоставительная типология татарского и русского языков: программа для педвузов” (2000), “Татар һәм рус телләрен чагыштырма аспектта өйрәнү: Укыту-методик кулланма” (2002), “Основы методики обучения чтению на татарском как неродном языке” (2002), “Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнү теориясе һәм практикасы” (2003), “Внутренний и внешний мир носителей татарской культуры через призму языка” (2003), “Этнокультурная лексика татарского языка” (2003), “Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы” (Педагогик белгечлекәр буенча УМО грифы белән, 2004), “Татарская культура в языковом отражении” (2004), “Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре” (2006), “Теоретические и прикладные аспекты татарской лингвокультурологии” (2009) һ.б.

## ЗӘКИЕВ МИРФАТЫЙХ ЗӘКИ УЛЫ
**(**1928 нче елның 14 нче августында туган**)**

Филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Россия лингвистик фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы һәм президиум әгъзасы, Ататөрек исемендәге Төрек фәнни лингвистик җәмгыятенең мактаулы хакыйкый әгъзасы, ТДГПУның мактаулы профессоры, Татарстандагы көнчыгышны өйрәнүчеләр фәнни җәмгыятенең мактаулы президенты, Бөтендөнья тюркология ассоциациясе президиумы әгъзасы М.З.Зәкиев 1928 нче елның 14 нче августында Татарстан Республикасы Ютазы районының Зәйпе авылында туа. 1951 нче елда Казан дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген бик яхшы билгеләренә генә тәмамлый.

1960-1965 елларда М.З.Зәкиев КДУның татар теле кафедрасы мөдире булып эшли. 1965 нче елда М.З.Зәкив КДПИда фәнни эшләр буенча проректор итеп билгеләнә. 1967-1986 нчы елларда ул бу уку йортының ректоры вазыйфаларын үти. 1976 нчы елда уку йорты Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә, ә 1978 нче

елда илебездәге 250 педагогик уку йорты арасында беренче урынга лаек дип табыла. Уку йортының әлеге һәм башка уңышларда җитәкче буларак Мирфатыйх Зәки улының да өлеше зур.

1986 елда М.З.Зәкиев Г.Ибраһимов исемендә Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры итеп билгеләнә. Җитәкчелек итү тәҗрибәсе, илдә барган үзгәрешләр институтның киңәю, эш юнәлешләренең артуына зур ярдәм итә. Нәтиҗә буларак, 1992 елдан республикада Фәннәр академиясе эшли башлый, Тел, әдәбият һәм тарих институты составыннан Татар энциклопедиясе һәм Тарих инситуты аерылып чыга.

Казан лингвистика мәктәбенең күренекле шәхесләреннән берсе булган Мирфатыйх Зәки улы татар телен, татар халкының этник тарихын, мәдәни һәм милли мәсьәләләрен бәйләнештә өйрәнә. Тел белгече буларак, М.З.Зәкиев татар теленең синтаксик төзелешен монографик өйрәнеп, әлеге юнәлештә фәнни эзләнүләргә нигез сала. Галим тарафыннан 700дән артык фәнни хезмәт язылган. “Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис.” (1958) хезмәте бүгенге көндә дә татар синтаксисы фәненең нигезен тәшкил итә. Башка телчелр белән авторлыкта дөнья күргән “Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков” (1977, 2007), “Волжские булгары и их потомки” (1993), “Төрки-татар этногенезы” (2003), “Тюрко-татарское письмо (история, состояние и перспективы)” (2005) хезмәтләре аның киңкырлы, тирән фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе булып тора. Галимнең 2003 елда дөнья күргән “Төрек һәм татарларның килеп чыгышы” монографиясе инглиз һәм төрек телләренә тәрҗемә итеп бастырылган.

1980-1990 нчы елларда М.З.Зәкиев – ТАССР Югары Советы рәисе һәм депутат. 1977-1986 нчы елларда ул – РСФСР Мәгариф министрлыгының милли филология буенча фәнни-методик комиссиясе рәисе. 1994-1999 нчы елларда – “Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы комиссия рәисе урынбасары. 1970-2002 нче елларда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирү комитеты әгъзасы була. 1970 нче елдан – тюркологларның Россия комитеты бюросы әгъзасы, Россия Фәннәр академиясе каршындагы “Тел һәм җәмгыять” фәнни советы әгъзасы, 1986-1992 нче елларда җәмгыяви һәм гуманитар фәннәр буенча республика советы рәисе, күп кенә бөтенроссия, Татарстан

һәм төрек журналлары редколлегияләре әгъзасы була.

М.З.Зәкиев күп санлы фән кандидатлары һәм докторлары әзерли. Тел белеме һәм тарих фәннәре өлкәләрендә ирешкән уңышлары өчен ул күп санлы бүләкләргә лаек булган. Мәсәлән, 1970 елда “ТАССРның атказанган фән эшлеклесе”, 1976 елда “РСФСРның атказанган фән эшлеклесе”, 1971 елда – Хезмәт Кызыл Байрак ордены, дистәгә якын медаль иясе һ.б.

## ЗИННӘТУЛЛИНА КЛАРА ЗЫЯ КЫЗЫ
(1935-2007)

Зиннәтуллина Клара Зыя кызы 1935 нче елның 2 нче августында Актаныш районы Иске Симестрау авылында дөньяга килә. Мәктәп елларында ук ул үзенең сәләтле булуы белән аерылып тора. Мәктәпне бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаганнан соң, Казан дәүләт университетының рус филологиясе һәм тарих факультетына укырга керә. 1958 нче елда университетны тәмамлаганнан соң Пермь шәһәрендә рус теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли башлый. 1962 нче елда Казанга әйләнеп кайта.

1970 нче елда милли телләр турындагы фәнни тикшеренүләргә киң офыклар ачыла. Югары уку йортының тел белгечләре төрки телләрне үзләштерүдәге уңышларны иҗади куллана башлыйлар. Бу вакытларда Клара Зыя кызы аспирантурага укырга керә һәм фәнни җитәкчесе М.З.Зәкиев киңәше белән, морфологиянең иң катлаулы мәсьәләләренең берсе – фигыль юнәлешләрен өйрәнә башлый. 1962-1964 нче еллар аралыгында ул КДУ аспирантурасында белем ала. Ә 1965 нче елда Клара Зиевна үзенең укыту эшчәнлеген КДПИ ның тел гыйлеме кафедрасында дәвам итә.

1968 нче елда К.З.Зиннәтуллина кандидатлык диссертациясен яклый. Оппонент булган күренекле тюрколог профессор А.А.Юлдашев яшь галимнең хезмәтен татар телендәге ачыш буларак бәяли.

К.З.Зиннәтуллина татар һәм рус филологиясе факультеты студентларына «Татар һәм рус телләренең чагыштырма типологиясе» курсыннан лекцияләр укый, «Татар фигыленең грамматик категорияләре», «Татар һәм рус телләрендә кушма җөмләләр» темаларына багышланган махсус курслар алып бара. 1973 нче елда Клара Зыя кызы тел белеме кафедрасы доценты була.

Соңрак КДПИ ның татар филологиясе һәм тарих факультеты деканы. 1999 нчы елдан – кафедра профессоры.

1972 нче елда кафедра доцентлары З.М.Вәлиуллина, М.Ә.Сәгыйтов, К.З.Зиннәтуллина тарафыннан студентлар һәм укытучылар өчен “Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе” дип аталган уку әсбабы нәшер ителә. Әлеге хезмәттәге “фигыль” бүлеген тулысынча Клара Зыя кызы яза. Шушы елларда КДПИ ның тарих һәм филология факультетларындагы студентлар “Татар теле һәм әдәбиятын, рус теле һәм әдәбияты”н укыту планы буенча белем алалар. Шуңа күрә студентларны кирәкле уку әсбаплары белән тәэмин итү максатыннан М.З.Зәкиев җитәкчелегендә кафедра укытучылары “Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков” китабын төзиләр. Авторларның берсе – Клара Зиевна үзе була. Татар тел белеменең үсеш дәрәҗәсе “Татар грамматикасының” өч томында да чагыла. Клара Зыя кызы әлеге хезмәтнең икенче томын төзүдә катнаша. Ул “Сыйфат”, “Алмашлык”, “Фигыль юнәлешләре”, “Хәл фигыль”, “Рәвеш” бүлекләрен төзи.

Профессор К.З.Зиннәтуллинаның җитди хезмәтләре, фәнни һәм педагогик фикерләре җәмәгатьчелек тарафыннан югары бәяләнә. 3 томлы “Татар грамматикасы”н төзүдә катнашканы өчен, Клара Зиннәтуллина Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

Клара Зыя кызы – югары һөнәри мәктәпнең почетлы хезмәткәре, Россия Федерациясенең халык мәгарифе отличнигы, “Хезмәт ветераны”.

## ИБРАҺИМОВ ГАЛИМҖАН ГЫЙРФАН УЛЫ
(1887-1938)

Галимҗан Гыйрфан улы Ибраһимов 1887 нче елның 12 нче мартында Уфа губернасы Стәрлетамак өязенең Солтанморат авылында дөньяга килә. 1909 елда Казанга килгән вакытта Г.Ибраһимов инде шәхес буларак формалашкан, белем туплаган була. Тел гыйлеме өлкәсендә ул теоретик һәм гамәли, бигрәк тә графика һәм орфография, лексикология (терминология), әдәби тел тарихы, туган телне укыту методикасы кебек мәсьәләләрне өйрәнә.

Телче буларак Г.Ибраһимов татар әдәби теленең нигезе итеп халык сөйләм телен алу тарафдары була. Аның тел белеме

мәсьәләләренә караган беренче мәкаләләре матбугатта 1910 нчы елда басыла башлый. 1911 елда ике мөһим хезмәте – “Татар сарыфы” һәм “Татар нәхүе” дөнья күрә. Бу дәреслекләр популярлык казана һәм 1918 нче елга кадәр икесе дә биш-алты тапкыр кабат басыла. XX гасыр башына кадәр татар теле грамматикалары рус яки гарәп теле үрнәгендә төзелгән була. Г.Ибраһимов исә, уңышлы дип тапкан теоретик һәм методологик принципларны икесеннән дә файдалана һәм беренче тапкыр татар теленең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен төгәл тасвирлый алган. Дөрес, гарәп теле грамматикасы тәэсирендә кайбер ялгышлыклар да булуы күзәтелә. Мәсәлән, тартым категориясен кушылып языла торган алмашлыклар дип билгеләү, фигыль юнәлешләрен гарәп телендәге фигыль баблары белән тиңләп карау һ.б.

Г.Ибраһимов татар телен укытуда үз методикасын эшкәртә һәм 1916 нчы елда “Татар телен ничек укытырга?” дип исемләнгән махсус методик хезмәтен бастыра. Галимнең тагын бер кызыклы хезмәте – “Татар сарыфлары”. Биредә автор татар теле грамматикалары тарихын анализлый. Татар алфавиты, терминологиясе мәсьәләләренә карата да Г.Ибраһимов читтә калмый, турыдан-туры проблемаларны хәл итүгә катнаша.

1917 нче елдан соң Г.Ибраһимов совет хокүмәте органнарында эшли, актив рәвештә җәмәгатьчелек эшенә катнаша. 1927 нче елдан соң, авыру сәбәпле, аның эшчәнлегендә сүлпәнлек сизелә. Бик күп татар интеллигенциясе вәкилләре кебек үк ул да 30 нчы еллар афәтен үз җилкәсендә татый. Күп елларга аның хезмәте онытыла, шәхси архивы да югала. Бары 1955 нче елда гына аның исеме аклана һәм хезмәтләре халкына кайтарыла.

## ИВАНОВ МАРТИНЬЯН
(1812 - ?)

XIX гасыр тюркологларыннан берсе булган Мартиньян Иванов, 1831 нче елда 19 яшендә Оренбург шәһәрендәге Неплюев кадет корпусын тәмамлый. 1832 елның март аенда Казан университетына килеп, татар һәм фарсы телләреннән имтихан тапшыра. Университет советы карары нигезендә аңа гимназияләрдә татар теле укыту, фарсы телендә укырга, язарга һәм шул тел грамматикасын өйрәтү хокукы бирелгән. Шул елдан ул Неплюев хәрби училищесы укучыларына татар телен укыта башлый.

Татар телен укытудан тыш, М.Иванов канцеляриядә шәрыкъ телләреннән тәрҗемә итү белән дә шөгыльләнә. Үзе укыткан лекцияләр нигезендә ул соңрак татар теле грамматикасын, татар хрестоматиясен һәм татар теле сүзлеген ("Татарская грамматика") төзи. Әлеге өч томлык хезмәтне ул 1839 нчы елда басмага әзерли. Кызганычка, Казан университеты типографиясендә басылган грамматика һәм хрестоматия өлешләре янгын вакытында юкка чыга, хезмәтнең бары 4-5 экземпляры гына калган булырга мөмкин. 19 нчы йөзнең илленче елларында И.Н.Березин һәм С.Кукляшев училищеда татар телен укытуда файдалану өчен китап-дәреслек булмавын белдерәләр. Шул сәбәпле, 1856 елда М.Иванов "Хрестоматия"нең икенче басмасын әзерли, әмма ниндидер сәбәпләр аркасында ул дөнья күрми кала. Хрестоматиянең бер кульъязма нөсхәсе Петербургта саклана. Сүзлекнең дә Казан университеты архивында сакланганлыгы төгәл мәгълүм түгел. 1942 елда "Отечественные записки" журналының 25 нче томында М.Ивановның грамматика һәм хрестоматиясе басылып чыгу турында һәм аларның югары бәяләнүе турында язма булуы билгеле.

Автор әлеге грамматикасын язганда И.Хәлфин, А.Троянский һәм И.Гиганов хезмәтләреннән файдалануын искәртә. Ул дәвердә татар әдәби теле формалашып бетмәгәнгә, Неплюев хәрби училищесында оренбург сөйләше укытылган. Автор еш кына сөйләшне кыргыз һәм казах телләре белән чагыштырып барган. Грамматика өч өлештән тора: беренче өлешендә татар язуы, авазлар системасы характерлана; икенче өлештә сүз төркемнәре; өченче өлеш исә, сүз тезмәләре хакында.

Хезмәт югары бәягә ия. М.Иванов татар укучысын И.Ф.Крылов, И.И.Дмитриев әсәрләре белән таныштырган. Автор беренче тапкыр татар теле стильләре турында сүз алып бара. Шул рәвешле, М.Иванов төрки-татар филологиясе тарихында күренекле урын алып торучыларның берсе.

## ИМАНАЕВ ШӘЕХГАТТАР ХӘСӘН УЛЫ
(1875-?)

Шәехгаттар Хәсән улы Иманаев – юрист, филолог, җәмәгать эшлеклесе – 1875 нче елда элекке Казан губернасы Алабуга өязе Тирсә авылында ахун гаиләсендә туа. Башта Уфада, аннан Казанда гимназиядә белем ала. Казан университетының хокук факультетын

тәмамлый, аннан соң 1901-1902 нче елларда тарих-филология факультетында да белем ала. Озак еллар Казан шәһәре судьясы булып эшли, коллежский асессор чинында отставкага чыга. 1911 нче елда адвокат хокукы ала. 1913-1914 нче елларда “Хокук һәм хәят” журналын чыгара, “Бәянелхак” газетасының соңгы редакторы була.

Ш.Иманаев “Татар теленең сарыфы вә нәхүе” дип аталган китабы белән тел белеме үсешенә дә өлешен кертә. Әлеге 102 битлек китап 1910 елда Казанда басыла. Китап шул чорда басылып килгән рус һәм француз телләре грамматикасы үрнәгендә төзелгән. Төп игътибар сүз төркемнәре һәм аларның категорияләренә юнәлдерелгән. Грамматикада беренче тапкыр бер составлы җөмләләр турында мәгълүмат бирелгән, билгелелек / билгесезлек турында шактый тулы язылган, туры һәм кире сүз тәртибе мәсьәләсе дөрес хәл ителгән.

**КАЗЕМ-БӘК АЛЕКСАНДР КАСИМОВИЧ**
(1802-1870)

Күренекле галим һәм педагог Александр Касимович (Мирза Мөхәммәт Гали) Казем-Бәк 1802 елның 22 июлендә Төньяк Иранның Решт шәһәрендә туа. 1811 елда ул әнисе белән Дербент шәһәренә күчеп килә, иң яхшы укытучылардан белем ала, 1822 елда Әстерханда яши башлый. 1826 елда Казем-Бәк Казанга килә, университетта фарсы, төрек-татар телләреннән лектор булып эшли. Ул төзегән “Төрек-татар теленең гомуми грамматикасы” Демидов премиясенә лаек була.

М.Казыйм-Бәкнең Казан университетында Көнчыгышның сирәк китаплары һәм кулъязмалар бүлегендә Кавказ, Иран, Урта Азия, Кырым тарихына караган хезмәтләре саклана. Шулар арасында тюркологиягә һәм төрки телләрне өйрәнүгә кагылышлы, бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмаган, Казан университеты басмаханәсендә рус телендә дөнья күргән “Төрек-татар теленең гомуми грамматикасы” дигән зур күләмле хезмәте (беренче басмасы – 1839 елда, икенчесе – 1846 елда) бар. Әлеге хезмәт чагыштырма грамматика буларак бәяләнә. Бүгенге күзлектән чыгып караганда, анда угыз һәм кыпчак төркемнәренә кергән телләрне чагыштырма рәвештә өйрәнү, алардагы аерымлыкларны билгеләү төп максат итеп алынган. Мирза Казем-

Бәкнең бу хезмәте XIX гасырның беренче яртысында язылган зур күләмле төрки-татар грамматикасы булып санала. Китапның күп өлеше турыдан-туры татар теле материалларына нигезләнгән.

М.Казем-Бәк Россиядә көньчыгыш илләренең тарихын һәм мәдәниятын өйрәнүгә күп көч куя. Казан һәм Петербург университетларында ул төзегән һәм эшкәрткән дәреслекләр, укыту ярдәмлекләре, укыту планнары һәм программалары озак вакытлар файдаланылганнар.

### КОРБАНГАЛИЕВ МӨХЕТДИН ХАФИЗ УЛЫ (1873-1941)

Мөхетдин Хафиз улы Корбангалиев 1873 нче елда элекке Вятка губернасы, Алабуга өязе Биектау авылында туа. Авыл мәктәбен тәмамлагач, 1889 нчы елда белемен арттыру максатыннан Казанга килә. «Казан укытучылар мәктәбе»нә укырга керә. Бу уку йорты («Казанская учительская школа») үзенең алдынгы укытучылары белән дә, яңача укыту ысуллары белән дә танылган була. Ул Казан укытучылар мәктәбен 1895 нче елда тәмамлый. Аннан соң Мамадыш өязе авылларында укытучы булып эшли, яңача укытуны яклап, мәктәпләрне үзгәртеп коруда күп эшләр башкара.

1910 нчы елдан М.Корбангалиевнең төрле фәннәргә караган дәреслекләре, методик кулланмалары дөнья күрә башлый. «Дәрес бирү нәмүнәләре», «Татар әлифбасы», «Хисап мәсьәләләре», «Җәгърафия» һ.б. Хосусый мәктәпләр һәм Ф.Аитованың хатын-кызлар гимназиясе өчен устав һәм программалар төзү дә аңа тапшырыла. 1912 нче елда чыга башлаган «Мәктәп» журналында аның мәкаләләре еш басыла. Татар мәктәпләре укытучысы һәм инструкторы буларак, М.Корбангалиев Корылтайларда актив катнаша, укытучылар өчен курслар ачуга да ярдәм итә, тел һәм укыту мәсьәләләренә, лингводидактикага зур игътибар бирә. Бу – аның «Ана теле нәхүе», «Ана теле сарыфы» (автордашлар – Г.Баттал, Г.Бәдигъ), «Ана теле дәресләре», «Олыларны укытырга өйрәтү юллары», «Риязият дәреслекләре» һ.б. хезмәтләрендә ачык чагыла.

М.Корбангалиев рус теле белән татар телен чагыштырма рәвештә өйрәнү һәм өйрәтү өлкәсендә күп хезмәт итә, дәреслекләр бастырып чыгара. Р.Газизов белән берлектә, 1928 нче елда «Руслар өчен татар теле дәреслеге» исемле китап төзеп бастыра. Бу дәреслек «икенче баскыч мәктәпләрнең бишенче класслары һәм зурлар

курслары өчен» төзелгән була.

М.Корбангалиевнең 1924 нче елда Р.Газизов белән берлектә төзегән «Опыт систематической грамматики татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» хезмәте татар телен рус теле белән чагыштырып өйрәнү өлкәсендә зур әһәмияткә ия. Бу кулланма үз вакытында татар телен өйрәнүчеләр өчен дә һәм аны укытучылар өчен дә бердәнбер кулланма булып санала. Телләрне чагыштырма планда өйрәнү юнәлешендә авторның дистәдән артык дәреслек һәм методик хезмәте бар.

## МАКСУДИ ӘХМӘТҺАДИ НИЗАМЕТДИН УЛЫ
**(Һади Максуди)**
(1868-1941)

Әхмәтһади Низаметдин улы Максуди 1868 нче елда Казан губернасы Ташсу авылында Низаметдин мулла гаиләсендә дөньяга килә. 1881 нче елда Казанга килеп, “Касыймия” мәдрәсәсендә белем ала. 1890-1892 нче елларда Күл буе мәдрәсәсендә яңа ысул белән укытучы булып эшли. 1894 елда Төркиягә китеп, андагы белем бирү системасы белән таныша. Казанга кайтканчы Бахчасарайдагы Зынҗырлы мәдрәсәсендә эшләп ала.

Ә.Максуди 1896 нчы елда Казанга кайтып, Казан укытучылар мәктәбендә имтихан тапшыра һәм укытучы дәрәҗәсен ала. 1903-1905 нче елларда Казан университетында хокук һәм педагогика бүлекләрендә лекцияләр тыңлый. Әхмәтһади Максуди 12 ел дәвамында татар телендә “Йолдыз” газетасын чыгара.

Галим буларак эшчәнлеген Ә.Максуди татар орфографиясен камилләштерүдән башлый. 1892 нче елда “Әлифба” бастыра, бу китап уңышлы була һәм утыз тапкырдан артык кабат бастырыла. 1910 елда аның татар теленең авазлар системасы, морфологиясе һәм синтаксисының төп мәсьәләләре урын алган ике дәреслеге – “Төрки сарыф” һәм “Төрки нәхүе” дөнья күрә. Автор шул заманда басылган гарәп, фарсы, рус, француз телләре грамматикаларын күз уңында тотып эшләгәнгә күрә, нигездә яңа фикер юк һәм хезмәт шул елларда басылган башка грамматикалар белән аваздаш. Ул шулай ук рус теленнән дәреслек бастырган, татар терминологиясе, графикасы һәм орфографиясе мәсьәләләрен хәл итү юнәлешендә күп эшләгән.

1925-1930 нчы елларда Ә.Максуди Педагогика институтында гарәп теле укыткан. Галим 1934-1940 нчы елларда төрмәдә утыра. 1941 нче елда Казанда вафат була.

## МӘХМҮДОВ МӨХӘММӘД-ГАЛИ
(1824-1891)

Мәхмүтов Мөхәммәд-Гали – педагог, матур язу һәм китап миниатюралары остасы. Казан өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Биектау районы) Селәнгер авылында крестьян гаиләсендә туган. И.Хәлфиннан кала, Казан университетының Көнчыгышны өйрәнү бүлегендә икенче татар кешесе.

М.-Г.Мәхмүтов 18 яшендә университетта дәресләр бирә башлаган, ә соңрак Казанның I ирләр гимназиясендә каллиграфия фәнен укыткан. Ул халык авыз иҗаты үрнәкләреннән җырлар, әйтемнәр, табышлар һ.б. туплап бастырган, моннан тыш И.Хәлфин белән берлектә рус әдипләре әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп бастыру эшендә катнашкан. М.-Г.Мәхмүтов 19 нчы йөзнең 70 нче елларында Казан татар укытучылар мәктәбен оештыруда башлап йөри һәм 1876-1881 нчы елларда уку йортының инспекторы булып тора.

1857 елда М.-Г.Мәхмүтов “Практическое руководство к изучению татарского языка” хезмәтен бастыра. Бу кулъязма 1855 елда ук Казан университетының Көнчыгышны өйрәнү факультетында югары бәя алган була. 1867 елда Казандагы беренче гимназия ачылуга 100 ел тулу уңаеннан китап яңадан бастыруга әзерләнгән була, әмма басылып чыгуы билгеле түгел. Бу хезмәттә автор гарәп хәрефләре белән белдерелә торган татар авазларын рус телендәгеләре белән чагыштырып аңлата. Кулланма составына кертелгән сүзлек 3000 чамасы берәмлекне үз эченә ала һәм татар лексикографиясенең уңышлы гына үрнәге булып тора. Грамматика өлешендә М.-Г.Мәхмүдов сүз төркемнәрен карый. Аның фигыль сүз төркемен тәртипкә китереп, дөрес һәм төгәл тасвирлавын И.Н.Березин да югары бәяләгән. Татар теле синтаксисына караган мәгълүмат та бирелүе белән бу кулланма бай эчтәлекле хезмәт булып саналган.

Моннан тыш ул 1859 елда русча-татарсча сүзлек төзү юнәлешендә эш алып бара. Әмма бу сүзлекнең язмышы билгеле түгел. Автор 1851 елда рус теленнән татар теленә медицина

өлкәсенә караган шактый күләмле китапны тәрҗемә итә һәм шуның белән татар теленең фәнни хезмәтләр язу өчен яраклылыгын раслый.

## НАСЫЙРОВ ГАБДЕЛКАЮМ ГАБДЕННАСЫЙР УЛЫ
**(Каюм Насыйри)**
**(1825-1902)**

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров 1825 елның 14 (2) февралендә элекке Казан губернасы Зөя өязе Югары Шырдан авылында туа. К.Насыйри балалык чорын укымышлы гаиләдә, үзенең туган авылы Шырданда уздыра. Башлангыч белемне үз атасыннан ала. 1841 елда аны Казанның бишенче мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга бирәләр. 1855 елга кадәр, 15 ел шул мәдрәсәдә укып, гарәп, фарсы телләрен өйрәнүе өстенә, үзлегеннән татар әдәби телен дә камилләштерә. 1855 елда К. Насыйрины Духовное училищега татар теле укытучысы итеп чакыралар. Соңрак ул шул ук училищеның дәвамы булган Духовная семинариядә татар теле мөгаллиме булып эшли. 1879 елдан башлап, К.Насыйри үзенең барлык гомерен, рәсми рәвештә бер җирдә дә хезмәт итмәстән, тик язучылык эшенә һәм фәнгә багышлый. Аның зуррак күләмле фәнни һәм әдәби хезмәтләре менә шул вакытларда языла.

К.Насыйриның тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге аерым игътибарга лаек. Ул татар теленең әдәби һәм фән теле була алуын исбат итә. Аның башка телләрдән артта торуын фәкать эшләнмәгәнлегеннән генә күрә. Туган телебезне гамәли һәм фәнни эшкәртү юлында гаять кыю һәм зур эшчәнлек күрсәтә. К.Насыйри тел гыйлеме һәм сүзлекләр төзү өлкәсендә катлаулы һәм кирәкле эшләрне башкара. Татар теленең беренче аңлатмалы сүзлеген («Ләһҗәи татари», 1895) төзи. Русча-татарча һәм татарча-русча сүзлекләрне төзеп, бастырып чыгара. Математика, география һәм табигать фәннәре буенча киң массага аңлаешлы терминнар эшли. Дөрес һәм матур язу кагыйдәләрен күрсәткән беренче кулланманы («Кавагыйде китабәт», 1892) бастыра. Татар теленең фәнни грамматикасын («Әнмүзәҗ», 1895) төзүгә дә нигезне К.Насыйри сала. Хәзер дә әле ул хезмәтләр (бигрәк тә «Әнмүзәҗ») тарихи әһәмиятләрен һәм фәнни кыйммәтләрен югалтмаганнар.

Бер үк вакытта К.Насыйри рус телен үзләштерү өчен, беренче чиратта, уку китаплары төзи («Кавагыйде кыйраәте русия», 1889)

һәм рус теленең грамматикасын («Нәмүнә яки әнмүзәҗ», 1881) төзеп, аларны бастырып тарата. Бу эшләрен практик укыту процессында сынап, бер телне икенче тел белән чагыштыру методын кулланып алып бара. Ул рус, татар грамматикаларында булган яңалыкларны, аерымлыкларны, үзенчәлекләрне өйрәнә һәм аларны укучыларына төшендерә бара. К.Насыйри керткән бу яңалык хәзерге көндә дә балаларга икенче телне өйрәткәндә уңышлы методларның берсе санала.

**НУГАЙБӘК ГЫЙМАД ШӘРИФҖАН УЛЫ**
(1881-1943)

Гыймад Шәрифҗан улы Нугайбәк – тел галиме, 1881 елда Саратов губернасы Кузнецк өязе (хәзер Пенза өлкәсе) Черкеле авылында дөньяга килә. “Мөхәммәдия” мәдрәсәсендә белем алган. Биредә укыган елларында ук мәдрәсә җитәкчесе Галимҗан Барудиның ярдәмчесе булып эшләгән. Укуын тәмамлаганнан соң шул ук һәм башка мәдрәсәләрдә татар теле укыткан. Шул елларда Г.Нугайбәк татар әдәби телен камилләштерү, дөрес язу кагыйдәләрен эшкәртү юнәлешендә дә эзләнүләр алып барган. Нәтиҗә буларак, 1910 елда “Башлангыч” исемле китабы дөнья күрә. Татар әдәби телен камилләштерү мәсьәләсен ул өч төркемгә бүлеп карый: 1) татар телендәге сузыкларның саны һәм аларның язуда бирелеше; 2) татар теленең сүзлек байлыгын гомумиләштереп өйрәнү; 3) татар телен лингвистик терминнар белән баету.

Автор 1916 елда “Төрлек” исемле татар теле грамматикасы белән таныла. Әлеге хезмәтендә автор татар теленең авазлар системасын тасвирлый, аннан соң сүз ясалышы һәм сүз төркемнәре мәсьәләсен карый, шулай ук синтаксиска да урын бирелгән.

1912 нче елда аның “Сагынмалык” исемле китабы дөнья күрә. Г.Нугайбәк хезмәтләренең төп үзенчәлеге шунда, ул гарәп, фарсы, рус телләреннән кергән сүзләрдән арынып, чиста татар телендә язарга омтыла.

1912 елдан “Кояш” газетасы идарәсендә эшли. Инкыйлабтан соң, тел мәсьәләләренә кагылышлы булган мәкаләләре белән, матбугатта даими басылып тора. Озак еллар дәвамында Татарстан китап нәшриятында бүлек редакторы булып эшли.

Ул татарча-русча сүзлекләр төзү эшенә дә катнашкан. 1939 елда М.Корбангалиев, М.Гыймадиев белән авторлыкта “Русча-татарча

сүзлек. Башлангыч мәктәпләр өчен”; 1941 елда Ф.Махианов, Г.Шәфиев белән авторлыкта “Политик-экономик терминнар (русча-татарча)” китаплары басылып чыга.

## ӨМИДБАЕВ МӘХӘММӘТСӘЛИМ ИШМӨХӘММӘТ УЛЫ
(1841-1907)

Мөхәммәтсәлим Ишмөхәммәт улы Өмидбаев Уфа өязенең Ибраһим авылында туа. 1852 нче елда Оренбургта хәрби училищеда М.Бикчурин, Б.Айчуваков, С.Кукляшевлар укыткан чорда белем алган. 1879-1880 нче елларда Стәрлетамакта татар-башкорт балалары өчен ачылган рус мәктәбендә укыта. Уфа Диния нәзарәтендә тәрҗемәче булып эшли. 1887-1889 нчы елларда Кырымда эшләп кайта. Тәрҗемә әсәрләре, тарихи материаллар тасвирланган хезмәтләре, әдәби парчаларыннан тыш ул тел белеме өлкәсендә дә эзләнүләр алып барган. 1901 нче елда Казанда аның “Татар нәхүсенең мохтасары” исемле китабы басылып чыга.

## САФИУЛЛИНА ФЛЕРА САДРИ КЫЗЫ
(1938 нче елның 24 нче маенда туган)

Флера Садри кызы Сафиуллина 1938 нче елның 24 нче маенда хәзерге Тукай районы Теләнче Тамак авылында туа. Башта туган авылында сигезъеллык мәктәптә укый. Ул, урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, укытучылык һөнәрен сайлый, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем ала. Аннары университетның татар теле кафедрасында эшли.

Галимә 1992 елдан Казан дәүләт университетының “Чит телле аудиториядә татар теле укыту” кафедрасында эшли. Профессор Ф.Сафиуллина – 300дән артык фәнни, методик хезмәт авторы, шуларның җитмештән артыгы китаплар. Аның җитәкчелегендә һәм авторлыгында югары уку йортлары, мәктәпләр, колледжлар, гимназияләр өчен программалар, дәреслекләр төзелә.

Флера Сафиуллина татар теленең синтаксисы, татар теленең лексикологиясе, татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы, лексикография, татар телен чит телле аудиториядә укыту методикасы, мәктәп һәм вузлар өчен хәзерге татар телендә китаплар төзү юнәлешләрендә эшли. Ф.С.Сафиуллина татар телен

чит тел буларак өйрәнүчеләргә яхшы таныш булган “Татарский язык: Самоучитель” (1991), “Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь” (1996), “Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре” (2001), “Татарча-русча фразеологик сүзлек. Татарско-русский фразеологический словарь” (2001), рус мәктәбендә белем алучылар өчен төзелгән күп санлы мәктәп дәреслекләре авторы буларак билгеле.

Ул мактау грамоталарына, “Татарстан Республикасының атказанган укытучысы” исеменә (1993) лаек. 2000 елда Флера Садриевна ел хатын-кызы титулына лаек булган. 2001 елда К.Насыйри исемендә премия лауреаты, шул ук елда “Сөембикә” журналы тарафыннан бирелә торган “көмеш беләзек” бүләге иясе буларак билгеле. Татарстан Республикасы Президенты указы белән Флера Сафиуллинага “Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе” дигән исем бирелә (2004).

## СӘГЪДИ ГАБДРАХМАН ГАЙНАН УЛЫ
(1889-1956)

Габдрахман Гайнан улы Сәгъди – тел-әдәбият галиме, профессор. Уфа губернасының Златоуст өязе Тайми авылында мулла гаиләсендә туа. Туган ягында мәдрәсә белеме алганнан соң 1908-1911 нче елларда Истанбулдагы Дарелмөгаллимдә (Мөгаллимнәр әзерләү институты) укый. Россиягә кайткач, Актүбә, Алма-Ата, Екатеринбург, Бөгелмә шәһәрләрендә укыта. 1921-1925 нче елларда Ташкент уку йортларында укыта. 1925 елда Казанга кайтып һөнәри эшчәнлеген дәвам итә. 1930 нчы елда Сәмәрканд педагогия институтына күчә. 1949 нчы елда Нәвои иҗатын өйрәнеп, докторлык диссертациясен яклый. 1956 нчы елда Сәмәрканд шәһәрендә вафат була.

Г.Сәгъдинең иҗат эшчәнлеге 1910 нчы еллардан башлана. Ул үзенең күпсанлы хезмәтләре белән татар телен, әдәбятын, төрки әдәбиятларны, мәдәниятебезне фәнни һәм тарихи өйрәнү эшенә зур өлеш керткән. Аның татар тел белеме өлкәсенә караган хезмәтләреннән түбәндәгеләрне санарга мөмкин: “Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыфы” (Казан, 1913), “Үз телемезгә мөкәммәл сарыф, нәхү” (Казан, 1915).

## ТРОЯНСКИЙ АЛЕКСАНДР АЛЕКСЕЕВИЧ
(1779-1824)

Александр Алексеевич Троянский – тел белгече, педагог, галим. 1779 нчы елда Казан өязе Апаз авылында (хәзерге Арча районы) рухани гаиләсендә дөньяга килә. Бала чактан ук татар телен яхшы белә. Казанның Духовная семинариясендә белем ала. Семинариядә укыган вакытында үзлегеннән гарәп графикасын һәм мөселман терминологиясен өйрәнә.

1800-1818 нче елларда Казанның Духовная академиясендә беренчеләрдән булып, үзенең язмалары буенча татар телен укыта. 1814 нче елда митрополит Платонның Катехизисын татар теленә тәрҗемә итеп, бастырып чыгара. 1818-1821 нче елларда Казан өязе училищесында татар теле укытучысы итеп билгеләнә. 1821 нче елдан Казан семинариясендә татар теле укытучысы вазыйфасын башкара.

1814 нче елда Санкт-Петербургта "Краткая татарская грамматика, в пользу учащегося юношества, сочиненный Казанской Академии учителем татарского языка священником А.Троянским" китабын бастыра. 1824 елда китапның икенче басмасы Казанда дөнья күрә. Моннан тыш аның "Словарь татарского языка и некоторых употребительнейших в нем речений арабских и персидских, собранный трудами и тщанием учителя татарского языка в Казанской семинарии священника Александра Троянского" хезмәте дә барлыгы билгеле.

## ФӘЕЗХАНОВ ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАН УЛЫ
(1828-1866)

Хөсәен Фәезхан улы Фәезханов – күренекле галим, мәгърифәтче. Элекке Сембер губернасы Курмыш өязе Сабанчай (Сабачай) авылында туа. Казанда "Мәрҗания" мәдрәсәсендә белем алган, үзлегеннән рус телен үзләштерә. Ирекле тыңлаучы булып, Казан университетында лекцияләр тыңлый. Хөсәен Фәезханов үзе дә университетта Шәрыкъ телләре кафедрасында адъюнкт дәрәҗәсендә укыта. 1854 нче елда кафедра Петербургка күчерелү сәбәпле, шунда күчеп китә һәм 1862 елда шәрыкъ телләре лекторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ирешә.

Х.Фәезханов үзенең “Краткая учебная грамматика татарского языка” (1862) хезмәте белән танылa. Моннан тыш ул Фәннәр Академиясе тәкъдиме белән Тышкы эшләр департаменты архивында тикшеренүләр алып бара һәм кырым төркисендә язылган документларга нигезләнеп, “Кырым йортына вә ул тарафларга даир ярлык вә хатлар” исемле 940 битлек җыентык төзи. Хезмәт 1864 нче елда В.В.Вельяминов-Зернов сүз башы белән басылып чыккан.

1860 нчы елда Х.Фәезханов татар мәдрәсәләренә реформа уздыру мәсьәләсен күтәреп, аларда гимназия программасына нигезләнеп укыту турында проект төзи һәм хөкүмәт карамагына бирә, ләкин уңай нәтиҗә булмый. Гомумән, ул татар халкының югары белем алу мөмкинле хакында фикер йөртә, татар телендә газета һәм журналлар чыгару проектларын да эшләгән була. Шул ук елларда ул “Император Археология җәмгыяте хәбәрләре” журналында үзе өйрәнгән ташбилгеләр турында мәкалә бастыра.

1866 нчы елда кыргыз-казакъ урдасына барган гыйльми командировкасыннан кайтышлый, туган авылында 38 яшендә вафат була.

## ФӘЕЗХАНОВ ГАБДЕЛГАЛЛӘМ ФӘЕЗХАН УЛЫ
(1850-1910)

Габделгаллəм Фәезхан улы Фәезханов – язучы, тәрҗемәче. Элекке Сембер губернасы Курмыш өязе Сабанчай (Сабачай) авылында туа. Ул - мәшһүр мәгърифәтче Хөсәен Фәезхановның бертуган кече энесе. Казанда “Мәрҗания” мәдәрәсәсендә белем ала, 1880 елда Уфада Татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. Г.Фәезханов 1887 елда Казанда “Татар телигә кыскача гыйльме сарыф” хезмәтен бастырып чыгара. Моннан тыш ул 1888 елда “Гомуми җәгърафия” китабын бастыра. “Кәлилә вә Димнә”, “Шәҗәрәи төрки”, “Тутыйнамә” әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп чыгара. 1891 елда Казанда “Мөхәрри-әл-әфкяр” (“Фикерләр уяткычы”) исемле публицистик әсәре дөнья күрә һ.б.

Ул сәүдә конторасында хезмәт итә, Ташкент, Сәмәрканд, Маргилан, Мәскәү һ.б. шәһәрләргә барып йөри. 1910 елда Уфада вафат була.

## ХӘЛФИН ИБРАҺИМ ИСХАК УЛЫ

**(1778-1829)**

Ибраһим Исхак улы Хәлфин 1778 елда Казанда туа. Ул зур традицияләре булган укытучылар гаиләсендә тәрбияләнә. Бабасы Сәгыйть һәм әтисе Исхак кул астында бик яхшы белем алган 22 яшьлек Ибраһим Казанның I гимназиясендә татар теле укытучысы итеп билгеләнә. Университет ачылгач, анда татар теле буенча лекцияләр укый, ә 1823 елда адъюнкт-профессор дәрәҗәсен ала. Ул татарлардан беренче гыйльми дәрәҗә алучы кеше була. Бу мәртәбәне И.Хәлфин үзенең фән һәм мәгариф өлкәсендәге фидакарь хезмәтләре белән аклый.

Ибраһим Хәлфин фәнни-методик укыту әсбаплары булдыруга зур игътибар бирә. Галим буларак, аның татар тел белемен үстерүдәге хезмәте – "Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения" (1809). Анда татар әдәби теленең XVII-XVIII гасырлардагы төп нормалары чагыла. Грамматикада терминология татар, гарәп телләрендәге сүзләргә нигезләнгән.

Тюрколог буларак, И.Хәлфин борынгы төрки-татар язма истәлекләрен өйрәнүгә, аларны лингвистик яктан тикшерүгә зур игътибар бирә. Шундый хезмәтләрнең берсе – "Әхвәле Чыңгыз-хан вә Аксак Тимер" әсәре. Биредә моңа кадәр басылмаган, халыкта киң таралган риваятьләр, кыйссалар туплап бирелгән. Бу – укыту кулланмасы буларак, татар телендә беренче басма хрестоматия. Анда татар халкының язма байлыгы тупланган.

Ул, әтисе кебек үк, тәрҗемә эшләре белән дә шөгыльләнә. Аның тәрҗемәсендә Ф.Волковның "О привитии коровьей оспы" һәм "Наставление как распознать истинную смерть от мнимой" дигән китаплары (беренчесе 1803 һәм 1812, икенчесе 1813 һәм 1820 елларда) икешәр мәртәбә басылып чыга.

И.Хәлфиннең "Татар теле конспекты" фәнни һәм укыту-методик яктан әһәмияткә ия. Анда төрки тарихына бәйләнешле һәм татар теленең XIX гасыр башындагы торышы турында кыйммәтле фикерләр бар.

Ибраһим Хәлфин бөтен акылын, тирән белемен, фәнни эрудициясен, кайнар йөрәген халык мәнфәгатьләренә хезмәт итүгә багышлаган. Бу – аның мәгърифәтчелек эшчәнлегендә аеруча ачык күренә.

**ШАКИРОВА ЛИЯ ЗАКИР КЫЗЫ**

(1921 нче елның 9 нчы февралендә туган)

Педагогика фәннәре докторы, профессор, Россия Федерациясенең педагогика һәм иҗтимагый фәннәр академиясе академигы, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы Лия Закир кызы Шакирова 1921 елда Уфа шәһәрендә туа. Башкорт дәүләт педагогика институтын, аннан аспирантура тәмамлаганнан соң, 1948 елдан Л.З.Шакирова Казан педагогика институтынын рус теле кафедрасында эшли башлый. 1961-1963 нче елларда РСФСР ПФА милли мәктәпләрнең Фәнни тикшеренү институтының Татарстандагы филиалын оештыра һәм җитәкли, 1965-1990 елларда шул ук кафедраның мөдире вазыйфаларын башкара.

Л.З.Шакированың бөтен фәнни эшчәнлеге концептуаль һәм фактологик яктан төп мәсьәләләрнең берсе булган милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасына багышланган. Аеруча әһәмияткә ия булган хезмәтләреннән “Төрки телле мәктәптә вид һәм заман категорияләренә өйрәтү методикасының фәнни нигезләре” (1974), “Рус фигыле: теория һәм гамәл” (2007). Галимә татар һәм милли мәктәпләр өчен күпсанлы дәреслекләр төзегән һәм бастырып чыгара. Аның 350дән артык фәнни хезмәте лингводиактика өлкәсенә карый. Аның җитәкчелегендә ике дистәгә якын фән кандидаты һәм 3 фән докторы әзерли.

Фәнни-педагогик эшчәнлеге өчен Л.З.Шакирова Ленин ордены, Н.К.Крупская, “1941-1945 нче елларда Бөек Ватан сугышындагы фидакарь хезмәте өчен”, “Фидакарь хезмәте өчен” медальләре, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы белән бүләкләнә, Татарстан Республикасы Дәүләт бүләгенә ия.

## ХАРИСОВ ФИРАЗ ФАХРАЗ УЛЫ

(1952 нчы елның 24 маенда туган)

Педагогика фәннәре докторы, профессор, ТДГПУның укыту-тәрбия эшләре буенча проректоры, Россия Федерациясе югары һөнәри мәгарифенең мактаулы хезмәткәре. Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы Фираз Фахраз улы Харисов 1952 нче елда Башкортостан Республикасы Яңавыл

районы Истәк авылында дөньяга килә. Ф.Ф.Харисов хезмәт юлын 1969 нчы елда мәктәптән башлый. Совет Армиясе сафларында хезмәт иткәннән соң, югары белем ала, Казан шәһәренең партия, комсомол оешмаларында эшли. 1991 нче елдан бүгенге көнгә кадәр университетыбызда проректор вазыйфасын башкара.

Ф.Ф.Харисовның төп фәнни тикшеренү юнәлешләреннән лингводидактика, икетеллелек, рус мәктәбендә татар теле укыту методикасы мәсьәләләрен әйтеп үтәргә кирәк. Ул 300гә якын фәнни хезмәт авторы. Шуларның кайберләре: “Лингводидактические основы первоначального обучения татарской устной речи в русской школе” (1999), “Татар телен чит тел буларак өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре” (2001) һ.б.

Профессор Ф.Ф.Харисов докторлык диссертацияләре яклау буенча 2 совет әгъзасы. 1998 елда ул Каюм Насыйри исемендәге премия белән бүләкләнә.

## ХАРИСОВА ЧУЛПАН МӨХӘРРӘМ КЫЗЫ

(1953 елның 17 нче мартында туган)

Педагогика фәннәре докторы, татар тел белеме кафедрасы профессоры, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының атказанган мәктәп укытучысы Чулпан Мөхәррәм кызы Харисова 1953 елда Татарстан Республикасы Кукмара районының Сәрдек авылында туа. 1975 елда КДПИын бик яхшы билгеләренә генә тәмамлаганнан соң Зур Сәрдек мәктәбендә укытучы булып эшли. 1979 нчы елдан ТДГПУның татар тел белеме кафедрасында хезмәт итә.

Чулпан Мөхәррәм кызының фәнни-тикшеренү һәм методик эшчәнлеге түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла: хәзерге татар әдәби теле морфологиясенең актуаль мәсьәләләре; татар теленең сүз ясалыш үзенчәлекләре; татар телен мәктәптә укытуның лингвометодик нигезләре; татар теле морфологиясе һәм сүз ясалышына өйрәтүнең дидактик мәсьәләләрен эшкәртүдә аспирантлар эшчәнлегенә җитәкчелек итү. Галимәнең түбәндәге хезмәтләре аерым игътибарга лаек: “Мой первый татарский словарь” (1995, 2002, 2004 Ф.Ф.Харисов белән авторлыкта), “Обучение татарскому произношению в русской школе” (2001), “Татарский язык: теория и практика обучения” (2001) һ.б.

1998 нче елда Ч.М.Харисова Каюм Насыйри исемендәге премия лауреаты булды.

**ЮСУПОВ РҮЗӘЛ АБДУЛЛАҖАН УЛЫ**
(1938 нче елның 14 нче сентябрендә туган)

Филология фәннәре докторы, профессор, татар тел белеме кафедрасы мөдире, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт премиясе лауреаты Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов 1938 елда Әтнә (хәзерге Арча) районы Кышкар авылында туа. Авыл мәктәбендә укып, Казан кооперация техникумын тәмамлаганнан соң, Р.А.Юсупов Курган өлкәсенә эшкә җибәрелә. Өч ел Армия сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң 1960-1964 елларда КДУның тарих-филология факультетында белем ала. 1964-1967 нче елларда Казан телевидениесендә мөхәррир булып эшли.

1967 нче елдан алып бүгенге көннәргә кадәр Р.А.Юсупов ТДГПУнда хезмәт итә, 1986-2002 нче еллар аралыгында уку йортыбыз белән җитәкчелек итә. Халык депутатларының Казан советы депутаты (1989-1990), Татарстан Югары Советы депутаты итеп (1990-1995) сайлана, даими комиссия рәисе, парламент президиумы әгъзасы була. 1992-1995 нче елларда фикердәшләре белән берлектә оештырылган Татарстан Республика партиясен җитәкли.

Р.А.Юсупов инде озак еллар дәвамында студентлар, аспирантларның фәнни эшчәнлегенә җитәкчелек итә, кадидатлык һәм докторлык диссертацияләре яклау советы рәисе вазыйфаларын башкара.

Галимнең фәнни-тикшеренү эшчәнлеге юнәлешләре буларак түбәндәгеләрне санарга мөмкин: сөйләм культурасы, тәрҗемә теориясе һәм контрастив лингвистика. Аның 300дән артык фәнни хезмәте басылып чыккан. Шуларның кайберләре: “Рус һәм татар телләренең лексик-фразеологик берәмлекләре” (1980), “Җылы сүз җан эретә” (1996), “Әдәп башы тел” (2000), “Икетеллелек һәм сөйләм культурасы” (2003), “Тәрҗемә, чагыштырма типология һәм сөйләм культурасы мәсьәләләре” (2005), “Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы” (2007), “Тәрҗемә һәм сөйләм культурасы”

(2008) һ.б.

Р.А.Юсупов тарафыннан эшкәртелгән “Тәрҗемә теориясе һәм практикасы” программасы СССР Мәгариф министрлыгы тарафыннан илнең педагогик вузларына тәкъдим ителә һәм берничә тапкыр үзәк нәшриятларда басылып чыга.

Рус телле укучыларга татар телен укыту өчен рус телендә язылган дәреслекләр күп кирәк була. Бу юнәлештә язылган дәреслекләрнең кайберләрен әйтеп үтү кирәк: “Учащательная форма татарского глогола” (Н.И.Ильминский, 1863), “Первый опыт словаря народно-татарского языка по выговору крещенных татар Казанской губернии” (Н.Остроумов, 1976), “Грамматика народно-татарского языка” (А.Архангельский, 1894), “Русско-татарский словарь” (А.А.Воскресенский, 1894), “Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии” (Ш.Ахмеров, 1895), “Грамматика алтайского языка” (Н.И.Ильминский, 1896), “Материалы к изучению казанско-татарского наречия” (Н.Ф.Катанов, 1898), “Уроки татарского языка с воспоминаниями о них Н.П.Остроумова с приложениями Н.Ф.Катанова” (Н.Ильминский, 1914), “Опыт краткой крымско-татарской грамматики” (Н.П.Остроумов, 1916).

XX гасыр башында татар балаларына туган телне өйрәнү өчен дәреслекләр басылып чыга. Мәсәлән, «Сарыф төрки» (М.Ахундов, 1897), ”Сарыф төрки” (Г.Тәүфикъ, 1900), “Сарыф төрки” (Г.Начиз, 1900), “Төрки сарыфы” (Ә.Мөхәмәдрәхим, 1905). Татар теленең морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләрен өйрәнүдә үзләреннән өлеш керткән авторлардан Х.Кәбүтәри (“Кыскача татарча сарыф”, 1910), Г.М.Чыгътай (“Сарыф”, “Нәхү”, 1918, Уфа), һ.б. әйтергә мөмкин.

**ЭЧТӘЛЕК**

Курсның үрнәк программасы ...................................................... 3

Татар һәм рус телләрен чагыштырма өйрәнүгә хезмәт куйган галимнәр ........................................................................................ 13

**СОСТАВИТЕЛИ**

САТТАРОВА МАДИНА РАШИДОВНА
кандидат филологических наук, доцент

ХУСНУТДИНОВ ДАМИР ХАЙДАРОВИЧ
кандидат филологических наук, старший преподаватель

**НАУЧНО-МЕТОДИЧЕСКОЕ НАСЛЕДИЕ:**
**сопоставительное изучение языков**

Подписано в печать 17.02.11 г. Форм.бум. 60x80 1/16. Печ. л.2.75
Тираж 100. Заказ № --
Отпечатано с готового оригинал-макета в ООО “Вестфалика”
г. Казань, ул. Б.Красная, 67. Тел.: 236-62-72